**Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының«Акбаш авыл җирлеге " муниципаль берәмлеге составына керүче Акбаш тимер юл станциясе поселогындагы торак пунктта гражданнар җыены карары**

**"19" ноябрь 2025 ел № 2**
**15.00**
**Акбаш тимер юл станциясе поселогы,**
**Мәктәп урамы, 11а й.**
**КФҮ бинасы**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45 һәм 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Акбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Акбаш тимер юл станциясе поселогындагы гражданнар җыены нигезендә Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының " җирлеге

карар кылды:

1. 2026 елда Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Акбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Акбаш тимер юл станциясе поселогы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, тыл хезмәтчәннәреннән, мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә.

2.Җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:
- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (Акбаш тимер юл станциясе поселогы торак пунктының балалар мәйданчыкларына комлык, беседка, чүп савытлары сатып алу һәм урнаштыру)

**Гражданнар җыенында рәислек итүче,**

**«Акбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлек башлыгы**

**__________ Л. А. Малахаева**